
ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ МАЙ * 2019 * КАЗАН

6



Александр АЛЁШИН

АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

• АКШ Рәсәйнең оятсыз рәвештә үз-үзенең эшләренә тыгылуы турында белдерде.

• "Голос. Дети" конкурсы нәтиҗәләре өчен җаваплылыкны Рәсәйдә тыелган ИГИЛ үз өстенә алган.

• Рәсәйдә рәсми рәвештә асфальтны яңгыр астында да, кар яуганда да җәяргә рөхсәт бирелгән.

• Тикшерү комитеты Интернетта тентү чаралары үткәрә башлаган.

• Фейклы яңалыкларда тотылучы Сайт, мең лайк штрафка салынган.

• "Бэсэдэр ньюс" хәбәренчә, Израиль Зеленскийның милләте мәсьәләсендә үзенең бернинди катнашы юклыгын белдергән.

• Барлык дин вәкилләренең, иңгә-иң куеп, бергә гыйбадәт кылу урыны табылган – самолет.

• Экспертлар әйтүенчә, бездәге барлык нанотехнологияләрнең бары тик берсе генә яшәп китте – нанохезмәт хакы.

• "Балык тоту законы"на суалчан табу бүлеге кертелде. Ләкин аларны казып алу тыела, чөнки бу гамәл җир байлыкларын законсыз үзләштерү һәм эшкәртү статьясына туры килә.

• Украинада, сәяси яктан бик килешеп бетмәү сәбәпле, "комик" дигән сүз куллану тыела. Чөнки бу президентка төрттерү кебек кабул ителә. Шуңа күрә киләчәктә "комосексуалист" сүзе кулайрак саналачак.

• Алманиягә һәм Франциягә күчеп яшәргә теләүчеләр өчен гарәп теле курслары ачылачак.

• "Хоккей легендалары сериясеннән яңа диск чыгарылган. Анда Владимир Путинның иң яхшы голлары кертелгән.

• "Голос. Дети" проекты иң кечкенә балаларга сайлап алу системасының ничек эшләгәнен күрсәткән.

• Суд, ришвәтчедән ришвәт алып, аны, илдән чыгып качмаска дигән шарт белән, өенә кайтарып җибәргән.

• Роснанода инә күзе аша үтеп чыга алырдай нанодөя тудырганнар.

• Сәүдә үзәкләрендә ирләр өчен уен мәйданнары урнаштырачаклар.

• Пилотка самолётны утырткан өчен шулкадәрле көчле алкышлаганнар ки, ул хәтта икенче мәртәбә күккә күтәрелеп, яңадан төшкән.

• Акыллы альпинистлар төркеме Эверестны әйләнеп узган.

• "Мисс Таиланд" конкурсында ир кеше җиңү яулаган.

Василий АЛЕКСАНДРОВ



ШОМБАЙ
болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Күптән түгел Эчке эшләр министрлыгы полковнигы Захарченко куйган рекорд юкка чыгарылды. Тентү вакытында аның фатирында 8,5 миллиард сум табылган иде. Ә менә ФСБ полковнигы Черкаллинның өч фатирында инде 12 миллиард табылган. Бу кадәр акчаны алып чыгар өчен ике КамАЗ кирәк булачак, дип сөйлиләр...

Н. ГАЙНУЛЛИН

ЧАЛЛЫ

– Тагын берничә шундый тентү – һәм пенсия яшен кире киметергә мөмкин булачак, – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыкканнан соң.

Вячеслав ШИЛОВ


Ринат АБЗАЛОВ

ГЛАВНОКОМАНДУЮЩИЙ

Эштән кайткач, алҗып нәчәлникнең
Барлы-юклы усал сүзеннән,
Җаным бераз ләззәт алсын диеп,
Узамын мин бакчам эченнән.

Койма артыннан ук муен сузып,
Чәчәкләрнең көтә ап-агы;
Яшел елмаюда, шатлык белән
"Исәнме!" ди кишер сабагы.
Горур тотып сусыл байракларын,
Сәлам бирә миңа чөгендер;
Ә кабаклар мыеклары белән
Гусарлардан һич ким түгелдер...
Күкрәкләрен киергән помидорлар
Чиләкләргә көчкә сыярлар;
Сабак буйлап саф-саф тезелешеп,
Честь бирәләр миңа кыярлар!

Гаскәр рәтләреннән үткән кебек,
Түтәл арасыннан узганда,
Югарырак тоям мин үземне
Усал нәчәлниктан гына түгел –
Главнокомандующийдан да!



Сергей АНДРИАНОВ

Хәвефле имтихсан

Тиз дә уза инде вакыт! Әле күптән түгел генә мәктәптәге чыгарылыш имтиханнарындагы кичерешләр, җиңелчә дулкынлану, укытучыларның җитди, әмма игелекле карашлары, чәчәкләр һәм киләчәк турындагы якты хыяллар белән чикләнә иде...

«Чынлап та шулай идемени?» – дип сорар бүгенге мәктәпне тәмамлаучы укучы шикләнеп. Әйе, гомер-гомердән килгән белем бәйгесен укучылар һәм ата-аналар өчен мәхшәргә әйләндергән БДИ кертелгәнче нәкъ шулай иде шул. Хәзерге кебек полицейскийлар, металлодетекторлар, видеокамералар һәм Түбән Камадагы кебек, кыз балаларның эчке киемнәрен тентүләр, укучыларны имтихан бирә алмау белән куркытулар юк иде ул чакларда...

Диңгез артыннан килгән һәм заманында акыл ягыннан зәгыйфь булган балалар өчен уйлап чыгарылган яңа белем тикшерү ысулының өлкән сыйныф укучылары арасында очраган курку һәм стресс белән бәйле нерв өянәкләренә сәбәп булганлыгы беркемгә дә сер түгел. Ул гына да түгел... Кайчагында кирәкле балл җыя алмау куркынычы аларда хәтта якты дөнья белән хушлашу теләге уята.

Алтайда бер егет рус теле һәм математика буенча начар нәтиҗәләр аркасында үзен атып үтергән. Бурятиядә бер кыз бала имтиханнан соң таблеткалар кабул иткән. Воронеж өлкәсендә бер укучы, БДИдан куркып, башын элмәккә тыккан. Волгоград өлкәсендә 9 нчы сыйныфта укучы кыз да дәүләт аттестациясеннән соң үзенә кул салган...

Бу кара шаукым безнең республиканы да читләтеп үтмәде. Берничә ел элек Кайбыч районында мәктәпне тәмамлаган егет, имтихан нәтиҗәләрен көтеп тормастан, үзе теләп дөньядан киткән. Эшләр болай киткәч, Татарстанда тәҗрибә рәвешендә бердәм дәүләт имтиханын бетерү турында таләпләр яңгырый башлады. Казан мэры Илсур Метшин да БДИны «Освенцим һәм гестапо» белән чагыштыручы белдерү ясады. Әмма халык авазын ишетмәделәр. Аның каравы имтиханнар алдыннан Россия укучыларын ялгыш адымнардан саклау йөзеннән махсус программа булдырдылар. Быел мәктәпләрдә шул кысада җыелышлар уздырылачак. Анда психологлар ата-аналарны балаларына карата игътибарны ничек көчәйтергә икәнен өйрәтәчәкләр...


Бердәм имтиханны, күкрәкләрен киереп, соңгы укучыга кадәр яклаучы чиновниклар исә аның «укучыларга объектив рәвештә, тигез шартларда һәм тулы күләмдә үз белемнәрен һәм иҗади мөмкинлекләрен күрсәтергә мөмкинлек бирүе» турында шәрран яралар. Ә исән калганнары илнең теләсә кайсы уку йортына керә ала. Теләсә кайсы – монысы арттырыбрак әйтелгәндер. Мәсәлән, кайбер Мәскәү вузлары, Кавказдан килгән йөз баллы абитуриентлар һөҗүменнән соң, үзләрендә махсус әңгәмәләр һәм керү имтиханнарына охшаш чаралар оештыруны кирәк таптылар.

Ә «белемнәр һәм иҗади мөмкинекләр»гә килгәндә – бу турыда беренче сыйныфтан алып БДИ «убырлы карчыгы» белән куркытылган, ә чыгарылыш сыйныфында дәүләт имтиханы бирүнең мөһимлеге турында нотыклар тыңлап, тест җаваплары ятлау белән чиләнгән укучылар үзләре сөйли алыр иде. Ә бирә алмасаң нәрсә? Дөрес, урам себерүче буласың гына кала.

Күптән түгел мәктәптә мине физикадан укыткан укытучымны очраттым. Сүз иярә сүз китеп, кайчандыр дөньяда беренче булып саналган урта белем бирү системасының көлен күккә очырган реформалар турында сөйләшеп киттек. Төгәл фән теленә ияләнгән тәҗрибәле педагог бу юлы бик кыска булды. «Элек мәктәп белем бирә иде, хәзер БДИга әзерли» – диде ул.

Мәгариф министрлыгы, чәчрәп китсә дә, болай әйтә алмас иде!

Айдар ГАРАФОВ



Александр ШУЛЬПИНОВ

Рашат НИЗАМИ

АФӘРИН!

*Россиядә бәхетсезләр һәм хәерчеләр 19 миллион икән. Бөек Ватан сугышында без 20 миллион халыкны югалткан идек. Менә шушы статистика саннарына таянып, Алмаз Хәмзин тарафыннан язылган шигырь белән танышканнан соң...**


Ну, язган ул! Фаҗигаи хәлләр,
Язганнары җанны өшетә...
Безнең Алмаз "миллионер" булган, –
Миллионнар белән эш итә.

Яшәүләрнең ачысын тоя ул,
Сугыш авазларын ишетә...
Менәтерә, бизнес ачкан ласа, –
Миллионнар белән эш итә.

Шигырь калыбына салган хисе
Авыр-авыр уйлар уйлата.
Әйтер сүзен, әһле каләм булып,
Миллионнар белән уйната.

Актаргансың заман гөнаһларын,
Телең ачы синең – нәкъ әрем...
Шигърияттә һәм дә сатирада
Яңа юл ачкансың – афәрин!

* Бу шигырь "Чаян" журналының 5 нче санында басылган иде. (Автор искәрмәсе).



Илдар НӘФИЕВ

Илдус АЗИМОВ



Абау!

КИҢЛЕКЛӘР һӘМ МӨМКИНЛЕКЛӘР

Халыкара Knight Frank консалтинг компаниясе уздырган тикшерүләр нәтиҗәсе буенча Казан Россиянең сәүдә мәйданнары белән иң аз күләмдә тәэмин ителгән шәһәрләр исемлегенә кергән. Тикшерүчеләр белдерүенчә, шәһәрдә барлыгы 14 сәүдә үзәге эшли, ә шул ук вакытта башкалада яшәүчеләрнең сатып алу мөмкинлекләре югары икән. Казанлылар исә, үз чиратларында, аларда кибетләр җитәрлек дип саныйлар. Ә җитмәгән әйберләр исемлегенә алар хастаханәләр, балалар бакчалары һәм әлеге дә баягы сатып алу мөмкинлеген керткәннәр.

КИТАПХАНӘ КҮЛӘГӘСЕНДӘ

Казанның китап сөючеләре көтеп алынган китапханә урынына бүләккә тагын бер сәүдә үзәге алганнар. 2015 елда шәһәр Башкарма комитеты Бигичев урамында ике катлы китапханә төзелешенә рөхсәт биргән булган. Ләкин төзелеш эшләре тәмамлангач, бинада көтмәгәндә "сәүдә үзәге" дигән язу пәйда булган. Объектны башка максат өчен кулланган өчен хуҗаларга зур штраф яный.

УҢАЙЛЫ БИЗНЕС

Чаллыда бер бәндә гадәти булмаган бизнес ачып җибәргән. Ул кибеттән продуктлар урлаган, һәм шул ук супермаркетның почмагы артында аларны 50 прцентлы ташлама белән саткан. "Үзмәшгуль" гражданинны тоткарлаганнар, ул "товар алырга" биш тапкыр барып килергә өлгергән булган.

ТЫҢЛАУСЫЗ СИХЕРЧЕ

Казанда Совет районының җәмәгать судында сәер эш каралган. Суд приставы үз йомышлары белән йөрүче Әлфия Ж.ны... сихерчелектә гаепләгән.Имеш, бу хатын судьяның ишеге астына ниндидер орлыклар салган һәм шул ук орлыклар белән кар өстендә аның исемен язган. Пристав "сихерче"гә берничә тапкыр искәрмә ясаган, ләкин ул аларны игътибарсыз калдырган. Хәзер аны "судья йә суд приставы күрсәтмәләрен үтәмәү" статьясы буенча гаеплиләр.

һАВАЛАРДА ОЧКАН КОШЛАР КЕБЕК...




Юрий КУХАРЕНКО


Вячеслав ШИЛОВ


Валерий ТАРАСЕНКО

Ринат АБЗАЛОВ







Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

– Кемнәр генә дәгъва кылмый бу Пенсия фондындагы акчага... хакимият тә, һәм ВЭБ та, һәм Чубайс та...

– Әйе, тагын кемнәр әле... ничек... пенсионерлармы?

– Ә аларының, гомумән, моңа ни катнашы бар?

• • •

Бензинга акцизлар күтәрделәр, НДСны, пенсия яшен арттырдылар. Күрәсезме, ил ничек күтәрелә!

• • •

– Әти, сатып ал миңа Греммины!

– Булдыра алмыйм, аңа тавыш кирәк.

– Алайса миңа "Тавыш" сатып ал! Голос!

– "Голос"ны алам!

• • •

Әнисе улын уята:

– Тор инде, сиңа мәктәпкә барырга вакыт.

– Барасым килми минем мәктәпкә. Анда балалар бер-берсен кыйныйлар, ә укытучылар балаларны! Күрәсем дә килми!

– Улым! Сиңа мәктәпкә бармыйча калырга һич ярамый. Син бит директор!

• • •

Иреңнең кайнап чыкканчы ачуын чыгарырга ярамый, югыйсә ул, парга әйләнеп, очып китәргә мөмкин!

• • •

– Хәлләр ничек? Эш таптыңмы?

– Барысы да әйбәт! Телевидениедә эшлим. Яңалыкларга аңлатма бирәм.

– Алдый торгансыңдыр әле?

– Әйе. Эшем шундый булгач...

• • •

– Кызым, сез анда, авылда ничек яшисез?

– Әйбәт. Ирем мине ярата, кадерләп тота. Мин хәтта өйгә утын да кертмим... пуләннәр арттан үзләре очып керә...

• • •

Иремне эзләп, аның бөтен дусларына шалтыратып чыктым. Менә бу дуслык, ичмасам! Барысында да кунарга калган, җидесендә әле дә йоклап ята...

Александр СЕРГЕЕВ



Ринат АБЗАЛОВ

ТУА КҮРМӘСЕН...

Ил өстенә явыз дошман килсә,
Яу кырына китә бар ирләр.
Хаклык яклар өчен вакыт җитсә,
Зур мәйданга чыга шагыйрьләр.

Караңгылык төшсә ил өстенә,
Ач фәкыйрьне изсә тук байлар,
Кулларына үткен каләм тотып,
Бу дөньяга килә Тукайлар.

Җәмгыятьнең һәрбер почмагында
Ояласа комсыз, усаллар,
Туздырырга шакшы ояларны
Пәйда була Гамил Афзаллар.

Халкыбызның чиста карашына
Томан өрсә оятсыз мөртәтләр,
Кешеләрнең күзен ачар өчен
Мөдәррисләр туа, Зөлфәтләр.

...Бар дөньяның асты өскә килеп,
Алышынса байрак-әләмнәр,
Таш диварлар баскач туры юлда,
Үтмәсләнсә кыю каләмнәр –

Өстәгеләр! Сезнең шук ялчылар
Җиңдек диеп борын чөймәсен –
Шагыйрьләрдән
файда чыкмый, диеп,
Берәр... Ленин туа күрмәсен!



ПАНДУС БАРМЫ? БАР...

Кадерле "Чаян"! Белгәнебезчә, пандуслар – мөмкинлекләре чикләнгән, сәламәт булмаган кешеләр өчен, коляскалы әниләрнең эшен җиңеләйтү өчен уйлап табылган җайланма. Ләкин куелган пандусларга күз салсаң, исән кеше дә якын килмәслек баш әйләндергеч аттракционга тиң булып чыга... Бер уйласаң, мондый корылма акылга сыймас, гамәлгә ярамас хәл тудыра түгелме соң?..

"Әмәт" метросы станциясе Әмәт магистрале белән кисешә. Бер ягыннан менгәндә баскыч та, пандус та бар. Ә менә Даурская урамы ягыннан менгәндә баскыч кына. Магистраль аша үтәргә җәяүлеләр юлы каралмаган, шуңа күрә "күршедәге" пандус белән файдалану мөмкин түгел. Уң якта яшәүчеләр сул яктагы мөмкинлекләргә кызыгып карыйлар, ни өчен аларда пандус куелмаганга аптырыйлар, югыйсә коляскалы әниләр, йөри алмый торган авырулар бу якта да аз түгел бит... Бөтен яктан да уңайлы метроның мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана алмавыбыз борчый.

А. СӘЙФЕТДИНОВА

КАЗАН

Александр ШУЛЬПИНОВ



МАТУР ЯГЫ

Өлкән яшьнең бар бер матур ягы:
Яшьләргә ул үрнәк булырлык –
Зәгыйфь картлык якынайган саен,
Ир-хатында ныгый тугрылык...

Ришат МИРЗАЯНОВ

ЧИШМӘЛӘРНЕҢ КАДЕРЕН БЕЛМИБЕЗ

Хөрмәтле редакция! Бөтен нәрсәдә без Америка йогынтысына кундәм дәүләт вәкилләрен гаеплибез. Ә менә шуларның берсе булса да Актаныш районы, Адаево авылындагы чишмәне күргәне булдымы икән? Зур популярлык яулаган әлеге чишмәнең суы әйтеп бетергесез шифалы, тәме исә танылган грузин минералкасын хәтерләтә.

Ләкин популярлыкның икенче ягы да бар. Чишмә тирәсе чын мәгънәсендә чүплеккә әйләнде. Яр буе төзелеш калдыклары, көнкүреш чүп-чарлары белән тулды. Табигать кочагында ял итүчеләр, шашлык сөючеләр монда капчык-капчык чүп ташлап китәләр. Ә учак ягарга якын-тирәдә үсеп утырган матур агачлар киселә. Күңелле итеп вакыт үткәрер өчен кемдер агачтан өстәл белән утыргычлар да ясаган. Ләкин чүп-чар тутырырга контейнер куярга башларына да килмәгән. Буш пакетлар, пластик шешәләр чишмә суы агышына ташлана. Болай булса, берничә елдан боржомига тиң суны эчәргә яраксыз дип табачаклар...

Р. АРСЛАНОВ

КАЗАН

Ахирәтләр

– Сәлам, ахирәт! Монда бер эш килеп чыкты бит әле, очрашырга кирәк иде.

– Нәрсә булды?

– Болай гына аңлатып булмый, үзең килсәң шәбрәк булыр иде...

– Ни булды соң?

– Ярый, әйтим инде... Минеке синең Артурың белән гөмбәгә барганнар иде бит. Бер чиләк алып кайтты бу. Кич белән кызырып ашадык та агуландык икебез дә.

– Йә, шуннан...

– Үзем болай ничава, бер тәлинкә генә ашаган идем... Баш әйләнә, температура күтәрелде, төне буе бәдрәфтә утырып чыктым...

– Ә ирең?

– Ул бөтен табаны ашап бетерде.

– Аңа нәрсә булды?

– Нәрсә булсын! Сырхауханәдә ята... Табиблар аның янында ничектер бик шикле йөриләр... Нәрсә уйларга да белмим инде...

– Коточкыч! Ә Артурның миңа әлегә кадәр шалтыратканы юк әле...

Алексей УСТИНОВ тыңлап торды.





















Алексей МАМАЕВ

Александр БРЮХАНОВ

БӘХЕТ

Кешегә бәхет килде. Ә аның тимер ишеге өч йозакка бикләп куелган.

– Кем ул анда? – дип сорады хуҗа ишек артыннан.

– Бәхетең килде, ач...

– Сезгә кайсы фатир кирәк соң? – дип сорады югалып калган хуҗа.

– Синеке инде, ундүртенче... Бакыршин урамы, җиденче йорт.

– Ә кем кирәк?

– Син кирәк миңа, син, ач тизрәк... – дип дулкынлана башлый бәхет. – Миңа әле тагын унике урында булырга кирәк.

– Тагын йортта яшәүчеләр исемлеген сатканнардыр инде, – дип сукранды хуҗа. – Ә сез шулай да кем соң? – дип сорады ул тагын бер кат...

– Бәхетең мин, бәхетең! – Бәхет кыза башлады.

– Коллектор түгелме? – дип сорады хуҗа...

– Юк ла инде, – диделәр ишек артыннан.

– Бәрәңге, массажёрлар, яңа электросчётчиклар, газ тикшерүчеләр – безгә берни дә кирәкми, – дип кычкырды хуҗа...

– Нинди кешеләр соң сез? – үз бәхетегезне кертергә теләмисез!

– Тормыш өйрәтте – сак һәм уяу булырга, – диде хуҗа. – Берәр нәрсә кирәк булса, повестка белән чакырыгыз...

– Китәм менә хәзер, бәхетсез каласың... – Ишек артыннан бөтенләй өметсез тавыш яңгырады.

– Тукта, – диде хуҗа бераз уйланып торганнан соң. – Бик теләгәч, кер инде...

Ишек шыгырдап ачылды. Тик анда беркем дә юк иде.

– Йөриләр шунда кеше борчып, – дип мыгырданды хуҗа, – ичмасам, бер файдасы тисә иде... Бәхет, дигән була тагын... Аның нинди булганын белә микән соң үзе...

Анастасия ВАСИЛЬЕВА





Николай ВОРОНЦОВ



Абау!

АҢЛАШЫЛА ТОРГАН ТЕЛДӘ

Түрәләрнең әдәпсез һәм ахмак фикерләре халык арасында гыйбарәгә әйләнеп беткән. Бу эшне төзәтергә дәүләт идарәсенең РАНХиГС югары мәктәбе алынган. Ул "Дәүләт сөйли!" дип аталган белем бирү курслары ачып җибәргән. Хәзер дәүләт эшлеклеләрен халык белән дөрес итеп сөйләшергә өйрәтәчәкләр. "Аңлашыла торган телне" блогерлар, журналистлар, бизнес-тренерлар һәм федераль ведомстволарның матбугат сәркатипләре укытачак. Беренче дәрес губернаторның шәхси соравы буенча Түбән Новгород өлкәсендә уздырылачак.

ГЕННАР ТАБУ

2020 елда булачак "эшмәкәрләр елына" икъдисадый үсеш министырлыгы махсус программа эшләячәк. Бу программа россиялеләрдә "бизнес гены" эзләячәк. Генны һәр кешедә табарга мөмкиннәр, шуның өчен тикшерeләчәк аудитория бик киң: мәктәп балаларыннан алып олы кешеләргә хәтле. Төп максат "геннарны табу" һәм булачак эшмәкәрләргә төрле яклап ярдәм итү. Тик ИАЭ директоры Никита Исаев әйтүе буенча, ничек кенә бизнесны үстерү өстендә эшләсәк тә, икъдисад җилләре эшмәкәрләргә каршы.

АКЧАЛЫ ЭТӘРГЕЧ

Түбән Новгород өлкәсенең Саров шәһәрендә музыка мәктәбенең укытучысы ел ярым эчендә 80 сум стимуллаштыручы түләү алган. Укучысының отчет концертларга әзерләнгән һәм чыгыш ясаганы, төрле конкурсларда катнашканы өчен укытучыга... 1 сум өстәмә акча исәпләнгән. Шәһәр администрациясендә, бөтенесе дә закон буенча, дип белдергәннәр – түләүнең суммасын, мәктәпнең кеременнән һәм җирле бюджетның тулылануыннан махсус комиссия билгеләгән. Түләү күтәрелсен өчен, музыка мәктәбенә күбрәк акча эшләргә тәкъдим иткәннәр.

БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР – БЕРЕНЧЕ КЛАССКА


Франциянең Кретс-ан-Белльдон коммунасының башлангыч мәктәбенә сарыклар кабул иткәннәр. Мәктәпнең администрациясе, укучылар җитмәү сәбәпле, классларны киметергә дигән язу алган. Тик ата-аналар моңа каршы чыкканнар, чөнки бу очракта классларда кеше саны артачак. Ярдәмгә җирле көтүче килгән. Шәһәрнең мэры ризалыгын алып, ул мәктәпкә 15 сарык алып килгән һәм хәтта туу турында таныклыкларын да күрсәткән. Мәсьәләне болай хәл итү бөтен кешегә дә ошаган: администрация отчетларын бозмаган, балалар яңа классташларына шат, көтүнең белем бирү системасына кушылуы белән көтүче дә канәгать.



Валерий ТАРАСЕНКО



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Виктор ФЁДОРОВ

Евгений ОБУХОВ

ӨМЕТ — ЮЛӘРЛӘРДӘ

Безнең шәһәрдә сәламәтлек саклаучылар әллә инде бөтенләй акылдан шаштылар: юләрләр йортына шыр юләрләрне җыйганнар. Ярый әле алар тыныч холыклы булса. Ләкин бит болар бөтенләй ипкә кертеп булмастайларны тутырганнар?!


Бигрәк тә берсе, Хәрефҗан дигәне, китаптан аерылмый торганы. Төнлә бүлнис китапханәсенә кергән дә, һәр китапка автограф яза башлаган: "Кадерле медабыйга эволюция теориясенә каршы килгәне өчен. Депутат Валуев", "Хөрмәтле баш табибка. Дәваланырга, дәваланырга, дәваланырга! Телесәлам белән Елена Малышева", "Башбухка – бюджетны һич кичекмәстән приватизацияләргә дигән теләктә, ләкин баш эшләтеп! Ихтирам белән Чубайс..."

Автографлары ярап та торсын, ди, ул бит китапларны урлый башлады, туганнары күрешергә килгәч, яшереп, аларга биреп җибәрә һәм, әле ул гына җитми, бандероль ясап, шәһәрдәге хөрмәт казанган кешеләргә таратырга куша. Мэрга, "Ун ел үткәч" дигән китапны "Полковник Захарченкодан – җиңүче остазыма – түбәнчелек белән, җиңелгән укучысыннан", дип язып җибәргән. Мэрның язмага күз төшерүе була, акаеп кала – оп-па, үзәктән кармак! Тикшерүчеләр кулына да эләгә бу язу! Укып карыйлар да көләләр... Ә соңрак, документлар актарып карагач – берничә миллиардлык урлашу ачыла. Нәкъ теге ун еллык чамасына...

Икенче китап мэрның финанс буенча урынбасарына килеп төшә. "Которган акчалар" исемле китапка "Карак төрмәдә утырырга тиеш! Глеб Жеглов һәм Володя Шарапов" дигән автограф куелган. Урынбасар дерелдәп куя да, мэр янына чын күңеленнән акланырга кереп китә...

Менә шуннан соң башка түрәләр акылларына килә башлыйлар һәм бәланең кайдан чыгуын ачыклыйлар. Оптимизация, дигән булып, сәламәтлек саклау идарәсен куып тараталар, ә барлык юләрләрне өйләренә озаталар. Алар урынына, иллеләп, үзләренең куластына пенсиядәге үзгәртүләрне якларга чыккан эшләүчеләрне митингтан соң җыялар...

Хәзер безнең шәһәрдә тыныч һәм шаулап йөрүчеләр юк. Әйтерсең лә нанотехнологияләр йогынтысы тиде.



Илдар НӘФИЕВ



Алексей МАМАЕВ

Чиновник хатыны, эшләрен оста алып барып, миллиардер булып киткән.

Улы — дәүләт корпорациясе президенты, кызы – зур фонд башлыгы.


Ә бичара чиновник, гаиләнең хурлыгы булып, һаман үзенең өч тиенлек хезмәт хакында утыра. Адәм көлкесе!





Эрнест ДЫШАЕВ, «Чаян» № 2, 1999

– Бөтенләй акылыннан язды карчыгым – пенсияне күтәрсеннәр ди!



Виталий ФЕОКТИСТОВ, «Чаян» № 8, 1996

– Самолётны террорчылар эләктергән!

Маннур САТТАРОВ

ЗАМАНА ТАКМАКЛАРЫ

Ишегалдым түгәрәк,
Уйный сары күбәләк.
Фатир өчен түләү килгәч,
Хәлләр җыйдым чүгәләп.

Кремльнең морҗасыннан
Төтен чыга ишелеп.
Чиновникка оклад арткан,
Калганнарга киселеп.

Өстеңдәге күлмәгеңнең
Якаларын кем уйган?
Депутатка, елы чыккач,
Ун пенсия кем куйган?

Поезд килә сызгырып,
Чуен юлны кыздырып.
Район башы сарай салган
Алпавыттан уздырып.

Байлар, байлар бал эчә,
Урта байлар сыра эчә.
Эшләп ярлы калган халык
Краннардан су эчә.

Хамис БАТЫРОВ

БЕЗ

Даһи Сталин, күп яшә, дип
Җырлап йөргән сабыйлар без.
Хрущёв чәчкән кукурузны
Чәйнәп үскән наныйлар без.
Брежневка дистә ярым
Орден аскан абыйлар без.

Ельцин илне таркатканда
Сүз әйтмәгән агайлар без.
...Хәзер инде ВВПга
Дан җырлаучы бабайлар без...

Әхсән БАЯН

ТИТУЛ

Иҗатым юк дип кайгырма,
Алырга тырыш титул.
Бөтен кирәк-яракларны
Титул хәл итә бит ул.

2002

Александр АЛЁШИН



Виктор ФЁДОРОВ





Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Матурлык салоны ишегендә белдерү:

Бездән чыгып килүче чибәрләр белән танышырга тырышмагыз – аларның берәрсә сезнең әбиегез булып куюы мөмкин!

• • •

Хатын-кыз – кредит картасы кебек. Син аңа нихәтле акча салма, барыбер бурычлы булып калачаксың.

• • •

– Доктор, миннән башка берәр авыру табыгыз әле! Монысына түләрлек акчам юк минем.

• • •

– Әле мин бик тә шәп икәнмен! – диде тормыш, телевизор караганнан соң.

• • •

Хатын ирен ял йортына озата.

– Кадерлем, зинһар өчен, анда өйдә бушлай да алып булырлык нәрсәләргә акча әрәм итәсе булма!

• • •

– Сөйлә, мәктәптә эшләрең ничек бара?

– Начар. Укытучы һаман сорый да сорый. Ул үзе бернәрсә дә белми бугай.

• • •

Һәр гаиләнең буыннан-буынга калдырып килә торган әйберләре була – гореф-гадәтләр, истәлекләр, йолалар, эчкечелек...

• • •

– Минем җәйгә бераз гына акча җыясым килә.

– Нәрсә, җәй хәзер түләүле мәллә?

• • •

– Сине уңышлы өйләнгәнсең дип ишеттем?

– Юк, тәрәзәләре тагын ишегалдына карый.

• • •

– Нигә син шундый коры һәм җансыз?

– Чөнки кемдер минем бөтен канымны эчеп бетергән...


• • •

– Сәлам, ничек яшисең?

– Хезмәт хакыннан хезмәт хакына хәтле: әтинекеннән әнинекенә хәтле дип әйтүем.

• • •

– Шәһәребез бик кечкенә – әдәпле кызга кияүдән башка чыгар урын да юк!



БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Франциядә "сары жилет"ларның протест демонстрациясе дистәдән артык булды инде, анда 30 меңләп кеше катнаша. Ә бездә, Хәтер көненДә, нибары 80 ләп кеше җыйнала. Оят...

Алмаз Хәмзин: Французларның хәтере яхшы, алар мескен дә түгел, "Сары жилет"лык акчабыз да юк бит әле безнең...

Р. Н.: Сагыш – хәсрәт дигәндә, ачы тәҗрибә шуны күрсәтә – берәүнең дә "амбары" буш түгел.

А. Х.: "Амбар"ларга гыйбдилык тутырдылар.

Р. Н.: Бензинга ничә тапкыр бәяне күтәрделәр. Мин аны, машинам булмагач, пычагым да сизмәдем!

А. Х.: Әлбәттә, сизмисең, минем машинага утырып йөргәч...

Р. Н.: Ни хикмәт: бездә асфальтны өч тапкыр җәяләр – яңа-биек йорт салгач, җылылык торбасын түшәгәч, һәм ниһаять, телефон кабеле үткәргәч...

А. Х.: Һәм дә әле ул кабельне казып кабат урлагач, дүртенче мәртәбә...

Р. Н.: – Бабам Низами: "Киленең ачуланса – бишек бавын тот, кияվең ачуланса – ишек бавын тот", – дия торган иде.

А. Х.: – Ә хатының ни әйтер иде. Эш ачуланышып аерылышуга килеп терәлсә һәм милек бүлә башласагыз?.. Нәрсәсен тот дияр иде микән?

Р. Н.: "Ялганга нәфрәтем зур, ләкин кайчакны үзем дә ялганларга, алдашырга яратам", – диде берәү.

А. Х.: Менә инде ялганларга да өлгердең: "берәү" түгел – үзең!

Р. Н.: Ирләр бала таба торган булса, аларның холкы 180 градуска үзгәрер иде, мөгаен.

А. Х.: Аллам сакласын!..

Р. Н.: Туганнарың кырыклап булса, хатының бер генә!

А. Х.: Бу фикерең белән син инде 180 градуска борылгансың да бугай, Рашат дус?!

Р. Н.: Берәү дә бу фани дөньяга үзе теләп тумаган.

А. Х.: ...Ник туганыңа да үкенә башлагансың ахрысы...

МИН КОЯШ

Фәнил Гыйләҗев

Эштән кайтам кайчак туры,
Кайчак урау юллардан.
Кайтуымны көтә өйдә
Хатыным, ике балам.
Тәрәз челтәрләрен этеп
Куйганнар да, алты күз,
Урам якны күзәтәләр,
Күзәтәләр сабырсыз.
Күзләренә мин чалынсам
Көткәндә зарыгышып,
Нур чәчелә йөзләреннән,
Гүя йолдыз балкышы.

Гаилә дигән галәмнең
Мин – кучәре, кояшы.
Минем тирәли әйләнә
Аларның бар дөньясы.

Берәр кайда тоткарлансам,
Кайтмый торсам озаклап.
Өйдә йә яңгырлар ява,
Яки куба гарасат,
Яки кара болытларга
Күмелә бүлмә эче...
Өйгә атлап керер хәл юк,
Гүя, умарта күче
Шул мизгелдә сырып ала
Һәм күмеләм сорауга.
Хәтта кулдагы портфельне
Өлгералмыйм куярга.

Кайда булдың? Ниләр алдың?
Ник кайтмадың иртәрәк?
Түргә узар юлны алар
Куя шулай киртәләп.
Ревизия үткәрәләр
Капчык төбен актарып.
Хәтта мәтәлчек аталар
Мин кайтканга шатланып.
Юл тотсам аш бүлмәсенә
Шундук җитәләр чыгып.
"Пешә күрмәсеннәр!" – диеп,
Утырабыз борчылып.
Кайсы алга, кайсы янга
Кунаклап канат җәя.
Пешкән ризыкка тотына
Бирергә алар бәя.
Ансы кирәк, монсы кирәк,
Бу – салкын, бусы – кайнар...
Кичләрен шуларны көйләп
Күңелле үтә еллар.

Алар миңа ярдәмче дә,
Булышалар һәр эштә.
Шулай уза ял көннәрем,
Шулай үтә һәр кич тә.

Кояш булгач – кисешмәсен
Өчен орбиталары
Һәркайсына бер эш биреп
Көйлим планеталарны.
Һәркайсының җаен белеп,
Күңелен күрми чарам юк.
Йолдызларым үтә көйсез,
Гиперактив, яман шук.

Озатып кала, каршы ала
Тәрәзәдә алты күз
Һәр көн саен, мин – кояшны,
Хатыным һәм ике кыз.

ТАПКАННАР

Виктор ВЕСЕЛОВ

– Кадерлем! Мине котласаң була. Тестирование үттем, эшкә алдылар.

– Ну сибәсең борчакны! Детекторны алдый алдыңмыни?

– Мин дөресен сөйлим!

– Менә, инде алдадың да.

– Син нинди сорауларга җавап биргәнемне тыңла. Югары белемем бармы? Мин «бар» дидем.

– Соң сине бит беренче сессиягә кадәр үк куып чыгардылар.

– Димәк, минем «тулы булмаган югары белем». Бу инде почти бакалавр дигән сүз. Аннан соң компьютерда эшли беләсеңме дип сорадылар. Мин «әйе» дидем.

– Син бит электронка буенча хат та җибәрә алмыйсың!

– Миңа аның кирәге дә юк. Компьютерны кем сатып алды? Мин. Сатып алу эшләү түгелмени?..

– Сөйләп тә куясың инде син! Югары белем, компьютер... Йә тагын ниләр сорадылар?

– Автомобиль йөртергә хокукың бармы дип. Бар, әлбәттә!

– Син, ичмасам, Юл инспекциясенең ишеге кайсы якка ачылганын беләсеңме соң?

– Аны белү ник кирәк миңа? Мин бөтен хокукларымны Конституция буенча алдым!

– Их, үзем сораштырган булсам! Беренче җавапта ук тоткан булыр идем...

– Ә детектор тота алмады-ы! Һәм мине кабул иттеләр. Реклама бүлеге мөдире итеп.

– Эзләгән нәрсәләрен тапканнар икән. Димәк, аларга синең кебек алдакчы кирәк булган!



Ринат АБЗАЛОВ



Виктор БОГОРАД



Александр КОСМЫЛИН

Люция ӘБЛИЕВА



Җәйге матур көннәрнең берсендә гаилә дусларыбыз: "Алдагы шимбәгә берсүссез безгә кунакка киләсез", – дип кырт кистереп әйткәч, аптырабрак киттек. "Туган-көн мазар да түгел, Сабантуйлар да үтте, нинди кунак?" – дип соравыбызга, "Немецлар килә!" – дип җавапладылар. "Немецлар килә? Тәүбә, әстәгъфирулла! 22 июнь якынлаша дигәч тә, куркытмагыз әле алай ук", – дип сүзне, гадәттәгечә, шаяруга бордым. "И-и әллә нәрсәләр башыңа килә синең, Әкълимә! Биш ел элек Тәүзих Германиягә фермерлык хуҗалыгына тәҗрибә тупларга барган идеме? – дип аңлатырга кереште Фәрәзинә.

– Соң?

– Соң дип, шул инде менә, фермер хатыны белән безгә кунакка җыена.

– Тәҗрибә тупларгамыни?

– Нинди тәҗрибә, Әкълимә, нинди тәҗрибә?! Кунакка!

Нәкәнис барып җитте! Шулай диләр аны күптән. Дуслар дигәндә, без бер стакан суга сикереп, коры чыгарга да әзер! Шимбә көнне иртән иртүк, кытай базарыннан алган, "кешелеккә" кия торган киемнәребезне киеп, күчтәнәчләр төяп, дусларыбызга юлландык.

Бистәгә якынлашканда безнең арада бәхәс чыкты. "Син кунаклар белән аларча исәнләш, яме!" – дип кисәтте фәлсәфи фәннәр кандидаты булган ирем.

– Ничек була соң ул?

– Башыңны юләргә салма инде, "гутэн так"ны да белмәсәң!

– Каян белим? Безнең авыл мәктәбендә вәпше чит тел укытмадылар, аттестатымда сызык тора.

– Сугыш турындагы кинолардан "гутэн так", "ауф видэрзэен"нарны әйтерсең лә бер дә ишеткәнең булмаган!

– Ишеткән бар ла ул, аларның тәрҗемәсен кем белсен?

– "Исәнмесез" һәм "сау булыгыз". "Йа" – әйе була. Шуңа күрә кунаклар сөйләгәндә "йа", дип тик баш кагып тор.

"Туктале, – мәйтәм, – мине немесчәгә өйрәтеп барасың, Рәсәйгә килгәч, урысча белә торганнардыр. Ир минем авызны тиз япты. "Акча эшләргә, әй, тәҗрибә тупларга барсаң, син дә өйрәнер идең!"

Әйткәнемчә, бистә каладан ерак түгел. Ыспурлаша-ыспурлаша, килеп җиткәнебезне сизми дә калганбыз. "Гутэн так!" – дип килештереп, килеп кергән булдык инде. Алай читтән карап торганда кунаклар безнең кебек кешеләр – койрыклары-мазар күренми, мөгезләре дә юк. Бичәсе, ягъни аларча фрау, бигрәк ачык кеше булып чыкты, бертуктаусыз сөйли дә сөйли, сөйли дә сөйли. Ну, Тәүзих аңа кушылып нидер сөйләнеп утырган була инде. Хэрр-әфәнде дә, фрау пауза алганда, сүзләр кыстыргалый. Бераздан фрауыбыз миннән нидер сораштыра башлады. Ирем өйрәткәнчә, "йа", "йа", дип тик утырам. Инде мәйтәм, ялгыш дәүләт серен генә ычкырдырмасам ярый! "Ихь фәрштэә нихьт" дип әйт", – ди Тәүзих. "Анысы ни дигәнне аңлата?" – дип сорыйм. Мин сезне аңламыйм дигәнне икән. Кит инде, без авыл баласының теле әйләнерлекмени?! "И фәрештәкәем", – дип ялгыш ычкындырып җибәрсәң?!

Фәрәзинә аш-су бүлмәсе белән зал арасында чабып йөри. Өстәлгә бер әйбер китереп куя да "биттә" ди, икенче әйбер куя да "биттә" ди, теттерә генә немесчә, иптәшкәем! Мин утырам бер сүз әйтергә зар-интизар булып. Чит ил кунакларыбыз ник бер сүз әйтсеннәр урысча, йә булмаса безнеңчә. Тик үзләренең телендә сөйләнеп утыралар. Вәт, мәйтәм, халык! Әтү, бездә илле татар арасына бер урыс килеп кушылса, бөтенесе урысчага күчә. Минем дә эчем поша башлады. Нишләргә? Ни булса да булыр, ул булмаса, кыз булыр дигәндәй, тоттым да Хәмдүнә Тимергалиева репертуарындагы "Сана, кәккүк, сана таңнарымны, сана, кәккүк, сана төннәрне" өздердем. Немецларның күзе шакмак булды, әйкәйгенәм! Нүҗәли, Илһам абый әйтмешли, "Хәмдүш"ебезне анда да беләләр?! Булмас димә! Шулай дип уйлап та бетермәдем, тегеләр парлап: "Коккук, коккук, руфс аус дим валд", – дип җырлап җибәрделәр. Боларның да "Кәккүк"ләре бар икән ләбаса! Шуннан тегермән ташы әйләнеп китте, малай. Тәүзих баянда үзебезнең бию көйләрен тарта башлады. Биеп туйгач, немец абзыебыз авыз гармунында уйнап күрсәтте. Кыскасы, җырлап-биеп, рәхәтләнеп күңел ачтык.

Ярты елдан соң дусларыбызга Германиядән хат килеп төште. Безне дә алар белән бергә кунакка чакырганнар. Барабыз, барабыз, рәхәтләнеп туйганчы үзебезчә сөйләшеп, җырлап-биеп, кунак булып кайтабыз әле!



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 6 (1884) июнь 2019

Баш редактор
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш редактор урынбасары, баш рәссам:
А. АЛЁШИН
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Җаваплы секретарь: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Бүлек редакторлары: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА,
А. ХӘМЗИН, Л. ӘХМӘТОВА, Г. СӨНГАТУЛЛИНА,
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
языла алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 10.06.2019 ел.
Тираж – 1130 Заказ О-1436

**Редакциянең адресы: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.**
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!

ЖЫРЧЫ ЗӨФӘР ...
ЯЗ ЧӘЧӘГЕ
КОМПОЗИТОР ФАСИЛ ...
МЕЖА
ГЕРМАНИЯДӘ ТАШКҮМЕР БАССЕЙНЫ
ЯЗГЫ ЧӘЧҮ ТЕХНИКАСЫ
"ТӘРӘЗ САЕН ... ГӨЛ ҮСӘ"
ЧӘЧӘКНЕҢ ТӨП СЫЙФАТЫ
КОМПОЗИТОР ХӨСНУЛ ...
"ИРКӘМ, ... ИНДЕ"
"СИРЕНЬНӘР ХУШ ИСЛӘР ..."
...-МӘЗ
КУХНЯДА ДА ТӨЗЕЛЕШТӘ ДӘ
ТНВда ТАПШЫРУ (-4)
ЯКТЫ, НУРЛЫ (ФАРСЫЧА)
ГАРМУНЧЫ ... ТУИШЕВ
СУРӘТНЕҢ АРТКЫ ӨЛЕШЕ
ТАЛЧЫГУ
КОМБАЙН
СОВЕТ ТАНКЫ "... ВОРОШИЛОВ"
"БӨДРӘ ..."
"ЙОСЫФ ... ЗӨЛӘЙХА"
БАСУ
ШАГЫЙРЬ ШӘРИФ ...
ХӘРБИ МАШИНА
АТА-...
"АНДА ... СУЛАРЫҢ ГОМЕРЕМНЕҢ ЭЗЕННӘН АККАНЫ"
ДУС-...
ШАТЛЫК (-2)
ШАГЫЙРЬ ... НУРИ
АНТОНОВ САМОЛЕТЫ
"ОЗАТА ..."
ТУГАН ...
"ГАКЫЛГА НУР БИРГӘН ..."
СӘНГАТЬ ТӨРЕ
ТАРТТЫРГАН ЯРМА
"ГӨЛГӘ КҮМЕЛГӘЧ ..."
ПИОНЕРНЫҢ ДУСТЫ (-3)
"ЧӘЧӘК АТА ГӨЛЕМ"
АТМОСФЕРА КҮРЕНЕШЕ
БАЛА ИСКЕЧӘ
"ЯКЫН ДУСТЫҢ БАРЫН ..."

Ринат АБЗАЛОВ төзеде

ТАБЫШМАК БИЛ АЛЫШМАК

1. Интернетта үзенең профилен япкан хатын-кыз ир кешедән нәрсәсе белән аерылып тора?

2. Кара тишекне телескопсыз ничек күзәтергә була?

3. Кешене бизи торган тыйнаклык ничек дип атала?

4. Түрәнең гадел икәнен ничек белеп була?

5. Ахыргача алып бара торган транспорт.

6. Шөгыльләнгән вакытта ятып алырга була торган бердәнбер спорт төре.

7. Түләүсез бердәнбер электр чыганагы.

ҖАВАПЛАР

1. Әгәр дә хатын-кыз интернетта үзенең профилен ябса икән, димәк, ул кияүгә чыккан. Ә ир кеше – димәк, "янган". 2. Үзеңнең акча янчыгына карарга кирәк. 3. Бижутерия. 4. Моңсу күзләреннән. 5. Катафалк. 6. Бокс. 7. Яшен.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исеме укыгыз. Журналыбызның 5 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **"СИН ГОМЕР АГЫШЛАРЫМ"**.

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
Ф. ГАРИПОВА (Сарман.),
Р. ЗАҺРИЕВ (Кукмара р-ны, Югары Арбаш ав.),
З. МӨХТӘРОВ (Тәтеш р-ны, Кече Тархан ав.),
Ә. ХӘСӘНОВА (Чаллы),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Кече Тарханнан

Зөфәр МӨХТӘРОВ!

Сергей ТЮНИН **ШАЯРТА**





